ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының алтынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының алтынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларын раслау турында.
3. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 12-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш)
4. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 8-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
5. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 36-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 37-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 38-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеген төзү, аның чикләрен билгеләү һәм аңа шәһәр округы статусын бирү турында» һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында» 39-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасында стандарт торак сатып алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 34-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 35-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 31-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 33-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

13. «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 28-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын балигъ булмаганнарга сатуны тыю һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 32-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

15. 2020 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында.

16. 2020 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы проекты турында.

17. Аерым акционер җәмгыятьләрнең идарә органнарына Татарстан Республикасы вәкилләрен күрсәтү турында.

18. Казан шәһәрен урманлы-парклы яшел зона белән әйләндереп алу турында.

19. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында» 2019 елның 11 июлендәге 2983-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

20. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.21 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

21. «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итүнең илкүләм гарантия системасын үстерү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 843694-7 номерлы федераль закон проекты турында.

22. Хөкүмәт сәгате: «2020 елда коммуналь хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә тариф ярдәмендә җайга салу турында».

23. Төрлесеннән: Татарстан Республикасында җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүмат.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 17 декабре
№ 199-VI ДС